КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 август г.Казань № 809

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 сентябрь, 759 нчы; 2013 ел, 20 апрель, 272 нче; 2013 ел, 3 июль, 468 нче; 2013 ел, 18 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2016 ел, 16 сентябрь, 647 нче; 2017 ел, 2 август, 539 нчы; 2018 ел, 11 гыйнвар, 2 нче; 2018 ел, 9 апрель, 218 нче; 2018 ел, 24 август, 706 нчы; 2018 ел, 4 октябрь, 904 нче; 2018 ел, 23 ноябрь, 1041 нче; 2019 ел, 22 гыйнвар, 31 нче; 2019 ел, 21 июнь, 506 нчы; 2019 ел, 12 июль, 569 нчы, 2020 ел, 12 март, 185 нче, 2020 ел, 18 апрель, 305 нче, 2020 ел, 28 август, 750 нче, 2020 ел, 11 сентябрь, 824 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәне раслау хакында»;

преамбулада «һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2013 елның 11 июнендәге 493 номерлы карары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе (алга таба - Инспекция) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) һәм төбәк дәүләт лицензия контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле башкарма органы булып тора.

Инспекция үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында конкуренцияне үстерү максатларының һәм бурычларының өстенлеген тәэмин итә.

Инспекция үз компетенциясе чикләрендә федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.»;

1.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

1.3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

1.4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Инспекциянең структур бүлекчәләре булган районара һәм шәһәр торак инспекцияләре рәвешендәге территориаль органнары бар (алга таба - районара һәм шәһәр торак инспекцияләре):

Әлмәт районара торак инспекциясе

Бөгелмә районара торак инспекциясе

Алабуга районара торак инспекциясе

Казан шәһәр торак инспекциясе

Яр Чаллы районара торак инспекциясе

Түбән Кама районара торак инпекциясе

Чистай районара торак инспекциясе

Инспекция карамагында әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт торак (контроль) күзәтчелеге һәм төбәк дәүләт лицензия контроле функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлкәсендә Инспекция эшчәнлеген оештыру-техник, методик, мәгълүмати һәм эксперт белән тәэмин итү өчен дәүләт казна учреждениесе бар.

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Инспекция үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.”;

1.11 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Инспекциянең төп бурычлары:

дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм гражданнар тарафыннан торак законнарында, энергияне сак тоту турындагы һәм торак фондына карата энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнарда билгеләнгән (муниципаль торак фондыннан тыш) мәҗбүри

таләпләрне үтәгән өчен төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;

күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләүне һәм күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контролен гамәлгә ашыру;

техник документация һәм норматив хокукый актлар нигезендә күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау буенча республика адреслы программаларын гамәлгә ашыру кысаларында гамәлгә ашырыла торган күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауны тикшереп тору;

техник документация һәм норматив хокукый актлар нигезендә күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча республика адреслы программаларын гамәлгә ашыру кысаларында гамәлгә ашырыла торган күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тикшереп тору;

торак фондыннан файдаланганда һәм аны карап тотканда хокук бозуларны ачыклау һәм кисәтү, ачыкланган хокук бозулар буенча тиешле чаралар күрү.»;

2.2 пунктта «лицензияләү» сүзенә кадәр «эшкуарлыкны» сүзен өстәргә;

3.1 пунктта «гамәлгә ашыра» сүзләреннән соң «төбәк» сүзен өстәргә;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Инспекция үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү белән идарә итү (02.01.01);

муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә идарә итү (02.01.02);

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә итү (02.01.03);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән - гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм кулланучыларга сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.01);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән финанс-бюджет өлкәсендә контроль функциясен гамәлгә ашырганда (01.02.01);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

цифрлаштыру белән идарә итү (01.15);

Татарстан Республикасының ведомство дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01):

«социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.1);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда (02.03);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17);

муниципаль торак контроле органнары - «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә;

Россия Федерациясе Торак кодексының 165 статьясындагы 11 өлешендә билгеләнгән вәкаләтләр бирелгән җирле үзидарә органнары белән - төзелә торган килешүләр нигезендә;

күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә үз-үзен җайга салучы оешмалар белән яисә оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә юридик затларның башка берләшмәләре яисә күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарлар белән – килешүләр нигезендә;

торак милекчеләре ширкәтләренең, торак, торак-төзелеш һәм башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларының берләшмәләре (ассоциацияләре, берлекләре) белән - килешүләр нигезендә.»;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Инспекция үз компетенциясе чикләрендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү һәм күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле өлкәсендә Татарстан Республикасы территориясендә башкарма-боеру һәм күзәтчелек вәкаләтләрен һәм функцияләрен гамәлгә ашыра, аерым алганда:

Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлары белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләр реестрын төзи һәм алып бара;

вазыйфаи затка (вазыйфаи затларга) лицензиат, лицензия эзләүче квалификация аттестатларын бирә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында квалификация аттестатлары реестрын алып баруны тәэмин итә;

күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе (алга таба - лицензия комиссиясе) эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

судка лицензияне гамәлдән чыгару турындагы гариза белән (лицензия комиссиясе карары нигезендә) мөрәҗәгать итә;

лицензия эзләүчеләрнең һәм лицензиатларның лицензия таләпләрен үтәүләрен тикшереп тора.»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Инспекция үз компетенциясе чикләрендә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар тарафыннан торак законнарында, энергияне сак тоту турындагы һәм торак фондына карата энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы

законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәүгә төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) өлкәсендә Татарстан Республикасы территориясендә башкару-күрсәтмә һәм күзәтчелек вәкаләтләрен һәм функцияләрен гамәлгә ашыра, муниципаль торак фондыннан тыш:

а) торак фондыннан файдалануга һәм аның сакланышына карата таләпләр, шул исәптән торак биналарга карата таләпләр, алардан файдалану һәм аларны тоту, күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдалану һәм карап тоту, торак урынны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинага күчерүне гамәлгә ашыру тәртибе, күпфатирлы йортта биналарны яңадан планлаштыру һәм (яисә) яңадан урнаштыру тәртибе;

б) капиталь ремонт фондларын формалаштыруга таләпләр;

в) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы һәм (яисә) күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны төзүгә һәм аларның эшчәнлегенә карата таләпләр;

г) күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда урыннар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә таләпләр;

д) тиешле булмаган сыйфатлы һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыкны арттырып, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт белән идарә итү, аны тоту һәм ремонтлау эшләрен башкарган очракта торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләре;

е) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләре һәм торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләре;

ж) күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү, күрсәтүне туктатып тору һәм чикләү кагыйдәләре;

з) күпфатирлы йортлар һәм торак йортлар бүлмәләреннең энергетика нәтиҗәлелеге һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпләү җиһазлар белән тәэмин итү таләпләре;

и) ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата таләпләр;

к) күпфатирлы йортлардагы инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә таләпләр;

л) социаль файдаланудагы наем йортларында торак урыннары бирү таләпләрен.»;

түбәндәге эчтәлекле $3.6^1$ пункт өстәргә:

«$3.6^1$. Инспекция күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган махсуслаштырылган оешмаларның (алга таба - төбәк операторы) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә торак законнарында, энергияне сак тоту турындагы һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнарда билгеләнгән, торак фондыннан файдалануга һәм аның сакланышына карата, милек рәвешенә бәйсез рәвештә, таләпләрне үтәвенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.6² пункт өстәргә:

«3.6². Инспекция «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»
2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан торак законнарында, энергияне сак тоту турындагы һәм энергиянең нәтиҗәлелеген арттыру хакындагы законнарда билгеләнгән милек рәвешенә бәйсез рәвештә торак фондыннан файдалануга һәм аның сакланышына карата таләпләрнең үтәлешенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра, шул исәптән түбәндәге таләпләрне саклауда:

а) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт эчтәлегенә;

б) коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүне чикләүгә, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативлары составына, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативларын билгеләү шартларына һәм ысулларына, шулай ук коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәт күрсәтүләрне) куллануның билгеләнгән нормативлары күләмен нигезләүгә, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулы турында карар, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен нигезләүгә һәм мондый түләүнең күләмен үзгәртүнең чикле индексларын үтәүгә;

в) социаль файдаланудагы наем йортларында торак урыннар бирүгә;

г) системада мәгълүмат урнаштыру тәртибенә.»;

3.7 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.11 пунктындагы «в» пунктчасында «күзәтчелеге» сүзен «контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Инспекция түбәндәге хокукка ия:

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) һәм төбәк дәүләт лицензия контролен гамәлгә ашырганда профилактик чаралар һәм контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрергә;

ачыкланган хокук бозуларны кисәтү һәм (яисә) бетерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны, шулай ук мәҗбүри таләпләрне бозуларны булдырмау чараларын күрергә;

Административ хокук бозулар турындагы эшләрне Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Инспекция компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча карарга һәм хокук бозучыларны билгеләнгән тәртиптә административ җаваплылыкка тартырга;

җинаять эшләрен җинаять билгеләре буенча кузгату турындагы мәсьәләне хәл итү өчен, мәҗбүри таләпләрне бозуларга бәйле материалларны вәкаләтле органнарга җибәрергә;

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 12 өлешендә билгеләнгән очракларда судка мөрәҗәгать итәргә.»;

4.2 пунктта:

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) һәм төбәк дәүләт лицензия контроле алып баручы белгечләрнең квалификациясен күтәрү;»;

унбишенче абзацта «күзәтчелек» сүзен «контроль (күзәтчелек)» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының районара һәм шәһәр торак инспекцияләре башлыклары бер үк вакытта Инспекция башлыгы урынбасарлары булалар.»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Районнарара һәм шәһәр торак инспекцияләре башлыклары - Инспекция башлыгы урынбасарлары үз вазыйфасына билгеләнеп куела һәм Инспекция башлыгы вазыйфасыннан азат ителә.»;

5.2 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «гамәлдәге» сүзен төшереп калдырырга;

унынчы абзацта «зона һәм шәһәр» сүзләрен «районнарара һәм шәһәр» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацта «зона һәм шәһәр» сүзләрен «районнарара һәм шәһәр» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин